ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 409 от «27» 10 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 6 мартындагы 258 номерлы карарын үз көчен югалтты дип тану турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге №485-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Исполнительный комитет Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 6 мартындагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренә, аларның урынбасарларына һәм баш бухгалтерларына хезмәт өчен түләү һәм премияләр бирү күләмнәре һәм бу предприятиеләр җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы нисбәтенең иң чик дәрәҗәсе турындагы нигезләмәләрне раслау хакындагы» 258 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә секторына әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http:pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын
Башкаручы Р.М.Никифоров

0000012972